**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНСАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ КАЕНСАР АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ**

**КАРАР**

**30 ноябрь, 2024 ел** **№3**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында гражданнар җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.2025елда Кукмара муниципаль районының Каенсар авыл җирлеге Каенсар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яки аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су суырту манараларын һәм су саклау зоналарын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, су суырту манарасын буяу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;)

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Каенсар авылында юлларны карап тоту, тракторны карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм комплектлау әйберләренең запас частьләре, тагылма җайланмалар сатып алу,

тракторчы хезмәтләре күрсәтү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Мәктәп, Г. Тукай урамнарына, вак таш салып, юллар төзү һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; махсус техника хезмәтләре Каенсар авылында 1 Май урамындагы күпергә култыксалар урнаштыру, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Каенсар авыл җирлегенә элмә такталар сатып алу һәм урнаштыру, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; массакүләм ял итү урыннарын, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, массакүләм ял итү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.)

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар тоту, төзекләндерү, (Каенсар авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу, гербицидлар сатып алу, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;)

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенсар авыл җирлеге башлыгы И.Х. Исхаков